СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422701, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Высокая Гора, ул. Б.Красная, 113А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИЕКТАУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422701, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау авылы., Зур Кызыл ур., 113А йорт

тел./факс 8(84365) 74-7-79, e-mail: Vgor.Vsg@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
28.06. 2024 г.

КАРАР
№ 373

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 нчы статьясындагы 3 нче пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 нче елның 28 нче июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 нче елның 1 нче гыйнварына аерым салым түләүчеләр өчен саналган җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итмәгән очракта үлгән яисә вафат булган физик затларның бурычлары булу;

2) 2024 нче елның 1 нче гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

3) физик затларның Россия Федерациясе Салым кодексының 48 нче статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслый торган документлар түбәндәгеләр дип билгеләргә:

1) әлеге Карарның 1 нче пунктының 1 нчес бүлегендә күрсәтелгән нигезләр булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) вафат булуга бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәпкә алудан төшерү турында белешмәләр;

в) мираска хокук турында таныклык бирү турында белешмәләр булмау турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге Карарның 1 нче пунктының 2 нче пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда:

а) оешма, шәхси эшмәкәр, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик зат исәпкә алынган урын буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) салым бетерелгән норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында белешмәләр;

3) әлеге карарның 1 нче пунктындагы 3 нче пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган бурыч булуы турында белешмәсе.

3. Биектау авыл җирлеге Советы карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- "Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны, пени буенча бурычларны һәм әлеге салымнар буенча штрафларны түләтүгә" ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында 2019 нчы елның 29 нчы ноябрендәге 621 нче номерлы карарын;

- "Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында" 2023 нче елның 7 нче июнендәге 287 нче номерлы карарын.

4. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru адрес буенча интернет челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Биектау авыл җирлеге башлыгы А.А.Хабибуллин